| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>СРЕДНЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>УРТА ТИГӘНӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2019 с.Средние Тиганы № 5

**Алексеевского муниципаль районының**
**“Урта Тигәнәле җирлеге территориясендәге Түбән Тигәнәле авылында үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» , Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле җирлеге территориясендәге Түбән Тигәнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 12 нче ноябре көнне 14 сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле җирлеге территориясендәге Түбән Тигәнәле авылында 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар ,1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- урам утларын карап тоту;
- җирләү урыннарын төзекләндерү;

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Түбән Тигәнәле авылы, Үзәк урамы 45 йорт

5.Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы**
**Вазыйфаларын башкаручы,**
**Советның Рәислек итүчесе** **Э.М.Камалова**